Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№7 (58)
14 март 2013 ел

## • Универ хәлләре

**5-10 МАРТТА** Зәй шәһәрендә чаңгы ярышлары буенча **РОССИЯ ЧЕМПИОНАТЫ УЗДЫ**. Төрле шәһәрләрдән килгән 26 вуз командасы арасында КФУ чаңгычылары, көндәшләрен артта калдырып, гомумкоманда зачетында беренчелекне яулады. Команда составында А.Абляева, В.Абрамова, А.Гарифуллин, В.Ермилин, Р.Загреева, А.Лаврентьев, В.Мамкин, Ж.Муравьева, А.Николаев, Ю.Хальковалар бар иде. Аларның күбесе – ТРның җыелма командасы вәкилләре. Җиңүләре белән тәбрикләп, алга таба да зур үрләр яулауларын телибез!

• • • •

**7 МАРТТА** бердәм туклану комбинатында Казан университетының **ХАТЫН-КЫЗЛАРЫН ТӘБРИКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ**. «Ел хатын-кызы» дип исемләнгән чара бәйрәм концерты төсен алды. Ректор Илшат Гафуров һәм башка проректорлар уку йортыбызның «иң-иң» хатын-кызлырына төрле номинацияләрдә бүләкләр тапшырды. «Иҗади шәхес» номинациясендә газетабызның мөхәррире Динара Миннекаева җиңү яулады.

• • • •

КФУ республика районнары белән хезмәттәшлек чикләрен киңәйтүне дәвам итә. **11 МАРТ КӨННЕ УНИВЕРСИТЕТ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ ТӨЗЕДЕ**. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, КФУ ректоры Илшат Гафуров, ректор киңәшчесе, Вузга кадәрле, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры Людмила Нугуманова катнашты. Килешү кысаларында, КФУның институт һәм факультетлары белән берлектә, уку-укыту процессын камилләштерү мәсьәләсе буенча фәнни-тикшеренү эшләрен алып бару, мәктәп эшчәнлегенә заманча технологияләрне кертеп җибәрү, фундаменталь фәннәр буенча укучыларны индивидуаль рәвештә әзерләүне гамәлгә ашыру мәсьәләре белән шөгыльләнәчәк.

• • • •

Шул ук көнне **КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНА** Британия корольлек җәмгыятенең вице-президенты **МАРТИН ПОЛЯКОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘГЕ ДЕЛЕГАЦИЯ ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Университет белән танышу процессында аларның игътибарын Казан химия мәктәбе музее җәлеп итте, чөнки биредә Карл Клаусның «рутений» химик элементын табуы турындагы мәгълүмат та бар.

• • • •

**11 МАРТТА** Казан университетына Ростов өлкәсе губернаторы **ВАСИЛИЙ ГОЛУБЕВ КИЛДЕ**. Ул, КФУ Президенты Мәгъсүм Сәләхов белән бергәләп, Казан университеты тарихы музее экспозицияләре белән танышты, Ленин аудиториясендә һәм күренекле Актлар залында булды. Дәрәҗәле кунаклар китабына губернатор истәлеккә җылы сүзләр дә язып калдырды.

• • • •

**12 МАРТТА** Казанда **«ФӘН ГОРИЗОНТЛАРЫ-2013» БРИТАНИЯ-РОССИЯ СИМПОЗИУМЫНЫҢ ТАНТАНАЛЫ АЧЫЛЫШЫ УЗДЫ**. Симпозиумның үзенчәлеге булып яшь буенча билгеләнгән чик тора: оештыручылар һәм катнашучылар 45тән яшьрәк һәм кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң, 20 ел хезмәт иткән булырга тиеш. Анда Казан университеты да тәкъдир ителде: уку йортының данын Роман Жучков, Альберт Ризванов, Антон Кольчугин, Айрат Хасьянов, Гүзәл Ситдикова, Рөстәм Хаҗипов, Елена Шаһимәрданова, Гүзәл Вәлиева, Равил Фәхруллин, Сергей Харинцев, Алексей Яковлев, Лариса Фролова кебек яшь галимнәр яклады.

• • • •

Шушы көннәрдә КФУның Тарих институты гомуми тарих һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры **АЛЬБЕРТ ӘХМӘТҖАН УЛЫ БОРҺАНОВКА** ТР Президенты указы белән **«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГАН ФӘН ЭШЛЕКЛЕСЕ»** дигән исем бирелде.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Юлия Карлова фотосы

# Җиһанда – «Студентлар язы - 2013»!

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

ЯЗ ЖИТКӘЧ ТӘ, КЕШЕ ЯҢА СУЛЫШ БЕЛӘН ЯШИ БАШЛЫЙ. КӘЕФЛӘР ШӘП, ХӘТТА ТҮБӘДӘН ТАМГАН ТАМЧЫЛАР ДА СӨЕНӘ КЕБЕК, КОЯШ ТА БӨТЕН ҖЫЛЫЛЫГЫН БИРЕП БАЛКЫЙ. Ә УНИКС КОНЦЕРТЛАР ЗАЛЫ СӘХНӘСЕ ЯЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ КӨННӘРЕННӘН ҮК ЯЗ ҖЫЛЫСЫНА, ИЛҺАМГА ЧУМГАН ИҖАДИ, ЯҢА ИДЕЯЛЕ СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН БИЗӘЛДЕ, ЧӨНКИ ЕЛ САЕН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН «СТУДЕНТЛАР ЯЗЫ – 2013» ФЕСТИВАЛЕ ЯҢА ДӘРТ БЕЛӘН ҮЗ ЭШЕН КАБАТ БАШЛАП ҖИБӘРДЕ.

УНИКС көн саен шау-гөр килә: кемдер йөгерә, кемдер җырын, кемдер биюен кабатлый, икенчеләре бизәнә-ясана. 12 март көнне сәхнәдә Физика институты һәм юридик факультет студентлары үз талантларын күрсәтте. Беренче пәрдә ачылуга, залны үзенең «Курорт язы» исемле шоу-тамашасы белән юридик факультет студентлары сәламләде. Аларның чыгышлары «Some night» хоры белән башланып китте. Җыр-биюгә корылган әлеге тамаша залда утыручы тамашачы тарафыннан көчле алкышлар белән бәяләнде. Ә инде «Лига» бию төркеме, «Dominanta» квартеты, бу көнне сәхнәдә бердәнбер «Ялгыз Казан» татар җырын башкаручы Камил Вәлиев һәм Булат Әбраров дуэты күңелләрдә онытылмас хисләр калдырды. Беренче булып чыгыш ясау җиңелләрдән түгел, ләкин юридик факультет талантлары үз миссиясен югары дәрәҗәдә үтәде: жюри канәгать, зал көчле алкышлардан тынмады.

Икенче булып, бу көнне үз сәләтләрен Физика институты студентлары күрсәтте. Физиклар үзләренең чыгышларында физика закончалыкларына аеруча зур урын биргән. Алар физика законнарын дөрес һәм файдалы куллану турында юмористик видеоклип күрсәтте. Чыгышлары заманча биюләр, матурдан-матур җырлар, рок-төркем чыгышы белән үрелеп барды. Бер сүз белән, физиклар да тамашачыны үзенә җәлеп итә алды, сәхнәне төрле матур төсләр белән бизәде.

Шуны әйтергә кирәк: ике команда тарафыннан да вокал-соло номинациясендә чит телдәге җырларны башкаручылар күп булды. Жюри дөрес нәтиҗә ясагандыр, ә тамашачы бу көнне күтәренке кәеф белән тәмамлангандыр дип өметләнәм.

«Студентлар язы» фестивале – студент тормышының матур традициясе, аның бүгенгесе һәм киләчәге. Ямьле язның алдагы көннәрендә дә УНИКС сәхнәсе талантлы, креатив һәм иҗади, сәхнә сөючән студентлар белән тулып торыр дип ышанабыз. Бүген Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студентлары көч сынашты. 18 март көнне – Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты, Экология һәм география институты, 19 март көнне – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты, Филология һәм сәнгать институты, 20 мартта Икътисад һәм финанс институты, Педагогика һәм психология институты үз талантларын күрсәтәчәк. 20сендә – Яр Чаллы, 21 мартта Алабуга институты яшь йолдызлары балкыячак. Барыбызга да яңа җиңүләр телибез!

## • Чара

# Җангир хан исеме мәңгеләштерелде

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты

12 МАРТТА КФУДА XIX ГАСЫРНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ КАЗАХ МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ, КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ МЕЦЕНАТЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ БУЛГАН ҖАНГИР ХАНГА МЕМОРИАЛЬ ТАКТА КУЕЛДЫ.

Тантаналы чарада Көнбатыш Казахстан өлкәсе хакиме Нурлан Нугаев җитәкчелегендәге Казахстан делегациясе, Казахстан республикасының Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле вәкиле Галим Оразбәков, КФУ Президенты Мәгъсүм Сәләхов һәм тышкы багланышлар буенча проректор, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты директоры Линар Латыпов катнашты.

**Ахыры 2нче биттә.**



Юлия Карлова фотосы

• Хатирә

# Чын халык шагыйре

**Элвина НӘҖИПОВА,**
татар филологиясе бүлеге

ТАБИГАТЬ ЯЗГА АЯК БАСКАНДА, ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ИҢ ТЫЙНАК ШАГЫЙРЬЛӘРЕННӘН БЕРСЕ ИЛДАР ЮЗЕЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН «ӨЗЕЛМӘС КЫЛЛАР» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ КИЧӘ УЗДЫ.





■ «Гашыйклар тавы» драмасыннан өзек.

Күпме танылган шәхесләрне бүләк иткән безгә Башкортстан җөмһүрияте! XX гасырның икенче яртысы татар әдәбияты үсешенә лаеклы өлеш керткән шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев та Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый, пьесалар иҗат итә. Иҗат җимешләрен республика матбугатында бастырып, үз укучысын таба. Әнисенең бу еллар хакында әйткән сүзләре дә бар: «Укытучы буларак балаларның бигрәк тә инша язганда сүз табалмый интегүләрен белә идем. Шуның өчен мин аларга кечкенәдән үк төрле әкиятләр сөйли һәм шигырьләр укый торган булдым. Үзләреннән дә кыска-кыска шигырьләр ятлатам. Бу эш белән Нил дә, Илдар да мавыгып киттеләр. Экскурсияләрдән, урманнардан, җиләктән кайткач, үзләреннән сөйләтеп, күргәннәре турында язарга куша идем. Шулай итеп балалар шигырьләр яза башладылар. Илдар сугыш вакытында балалар өчен кечкенә пьесалар да язгалый иде. Аны Ямады һәм Максим авыллары клубларында куйдылар да әле. Балачакта Илдар Тукайны яратып сөйли иде, үскәч, күбрәк Такташка тартылуы хәтердә калган».

Илдарның беренче әсәрләреннән үк әдәби тәнкыйть аның иҗатындагы көйлелеккә, халыкчанлыкка, нечкә лиризм һәм җанга үтеп керерлек моң булуга игътибар итә. «Илдар Юзеев – без яшәгән заманның көен, аһәңен тапкан шагыйрь. Бу җәһәттән, ул халыкчанлыгы, ихласлыгы, моңы белән әсир иткән Илһам Шакировка бик якын». – дип яза Х.Туфан аның турында.

Һәр шагыйрь, һәр язучы иҗатында туган җиренә мәхәббәт җырлый. Илдар Юзеев иҗатында да туган як темасы аерым урын алып тора. Туган ягының сихри матурлыгы, чылтырап аккан чишмә тавышлары үсмер чагыннан ук шагыйрьнең күңеленә юылмаслык моң булып сеңеп кала. Туган ягыннан яшьлек елларында ук аерылса да, шагыйрь туган туфрагына эзен суытмый. Туган авылының чишмәләрен, кыр-болыннарын җырларына салып тибрәтә, туган нигезен, әнкәен сагынып өзгәләнә, авылдашларын сагыну-юксыну тойгыларын, ташлар эретерлек йөрәк җылысын җыр юлларына сала. Менә шуңа да аның җырларында каеннар, усаклар, чыршылар да җырлый, җырларыннан мәтрүшкәләр исе килә.

Илдар Юзеев хезмәт юлын журналистикадан башлый: бик күп журналларда эшли. 1977-1987 елларда Татарстан Язучылар берлегендә яшь авторлар белән эшләү бүлеге мөдире һәм идарә рәисенең урынбасары вазифаларын башкара.

И.Юзеев иҗаты әдәбиятның төрле өлкәләрен иңли: романтик, фәлсәфи рухлы лирик шигырьләр иҗат итүдән тыш, «Өчәү чыктык ерак юлга», «Тынлык белән сөйләшү», «Мәңгелек белән очрашу», «Соңгы сынау» поэмалары белән поэма жанрының мөмкинлекләрен киңәйтә, «Кыр казлары артыннан», «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?», «Гашыйклар тавы» кебек драма әсәрләре белән драматургиягә лирик аһәң алып керә.

«Миләүшә» исемле җыентыгына тупланган поэмалары һәм баллададалары өчен, шагыйрьләрдән беренче буларак, Татарстан яшьләре оешмасының М.Җәлил ис. Республика премиясенә, ә «Таш диварлар авазы» һәм «Өзелмәс кыллар» исемле поэмалары өчен 1980 елда Татарстанның иң дәрәҗәле бүләгенә – Г.Тукай ис. Дәүләт премиясенә лаек була. 1979 елда Татарстанның, 1983 елда Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр ала. 1986 елда «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнә. 1983 елдан – Татарстан Республикасының халык шагыйре.

Кичәдә Илдар Юзеевның тормыш юлы, иҗаты күз алдыннан узды. Әйтерсең, үзе дә безнең арада утырды. Улы Салават Юзеев төшергән фильмнан өзекләр ярдәмендә иҗатташ дуслары, яраткан укучылары әдипнең яңа сыйфатларын ачтылар. Каләмдәшләре дә аның белән бәйле хатирәләрне бик матур итеп сөйләде, кат-кат аның тапкыр телле, шаян булуына басым ясады. Студентлар да шагыйрь әйтергә теләгән хис-кичерешләрне тамашачыларга җиткерә алды. Татар филологиясе һәм сәнгать бүлеге студентлары Илдар Юзеев шигырьләренә иҗат ителгән җырларны да бик матур башкарды.

Дөньяга гап-гади авыл баласы булып аваз сала, балачагы, үсмер еллары гади татар авылында уза Илдар аганың. Мондый зур дәрәҗәләргә, халык мәхәббәтенә шактый эзләнүләр аша ирешә, армый-талмый эшли, иҗат итә ул. Тормыштагы һәр күренешкә, һәр вакыйгага үз карашы, үз бәясе булган, язмыш авырлыкларына бирешмичә, иҗади кыйбласына тугры калган тыйнак шәхес – чын мәгънәсендә халык шагыйре ул Илдар Юзеев.

• Чара

# Җангир хан исеме мәңгеләштерелде

**Башы 1нче биттә.**

«Без бүген истәлекле вакыйга шаһитләре, – диде бу уңайдан казах делегациясе әгъзасы, Җангир хан исемендәге Көнбатыш Казахстан аграр-техник университетының тарих-этнография музее җитәкчесе Нурҗан Туләпов. – Җангир ханга мемориаль такта куелу – уку йортыгыз тарафыннан татар һәм казах халыклары арасындагы дуслыкны хөрмәтләүнең иң югары ноктасы. Әлеге шәхескә мемориаль такта кую бик урынлы, чөнки ул Казан университетының дәрәҗәле әгъзасы, аның меценаты булган».

Җангир хан – Эчке (Бакый) урдасы ханы (1824-1845), Бакый урдасына нигез салган Бакый-ханның улы. Башлангыч белемне мулладан алган Җангир хан, соңрак әтисе кушуы буенча Әстерхан губернаторы С.Андреевский гаиләсендә тәрбияләнгән. Хан Европа белеме ала, рус, фарсы, гарәп һәм өлешчә алман телләрен белгән. Ул Казан университетынына еш килгән. Җангир хан университет китапханәсенә гарәп, фарсы һәм төрек телендәге алты кыйммәтле борынгы кулъязма бүләк итеп калдырган.

1844 елда Җангир ханның матди ярдәме белән Евразиядә беренче мәртәбә «Шәригать кануннарына кыскача кереш» дип аталган китап бастырыла.

Тантанада КФУ Президенты Мәгъсүм Сәләхов соңгы елларда университет һәм Казахстан белән мөнәсәбәтләрнең тагын да ныгуы хакында: «Казан университеты делегациясе Казахстанда булды, без нефть эшкәртүнең геологик мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган яңа җәмгыять оештырдык. Бу университетыбыз һәм Казахстан өчен бик мөһим», – дип билгеләп узды.

Н.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең тарихи бинасында мемориаль тактага чәчәкләр куйганнан соң, делегация Казан университеты тарихы музее экспозициясе белән танышты, Ленин аудиториясе һәм танылган Актлар залында булды.

КФУ һәм Казахстан Республикасы арасындагы хезмәттәшлеккә килгәндә, ул соңгы елларда, чыннан да, аеруча актив үстерелә. М.Ауезов ис. Көньяк Казахстан дәүләт униерститеты, М.Үтәмешев ис. Көнчыгыш Казахстан дәүләт университеты, Д.Серикбаев ис. Көнчыгыш Казахстан дәүләт техник университеты белән килешүләргә кул куелды. 2012/13 уку елында КФУда Казахстаннан килеп укучылар саны йөз уникегә җитте. 2012 елда исә Казан университетыннан алтмыш биш кеше казах уку йортлары һәм оешмаларына җибәрелде.

Университетның дәрәҗәле кунаклары китабына Нурлан Нугаев: «Чын күңелдән бөтен укытучы-профессорлык составына, белем алуга кагылышы булган һәркемгә саулык, уңыш һәм рәхмәтле, вөҗданлы студентлар телим», – дигән сүзләр язып калдырды.

• Дуслык дәресе

КЫТАЙ БЕЛӘН КАЗАН АРАСЫ ЕРАК ДИСЕЗМЕ?! ЮК ЛА, НИБАРЫ АЛТЫ МЕҢ КИЛОМЕТР. СТУДЕНТЛАР ӨЧЕН НӘРСӘ ИНДЕ УЛ? ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ГЕОГРАФИЯ ИНСТИТУТЫНДА СОЦИАЛЬ-МӘДӘНИ СЕРВИС ҺӘМ ТУРИЗМ БЕЛГЕЧЛЕГЕН АЛУЧЫ СТУДЕНТЛАР ЧИТ ИЛДӘН КИЛГӘН ЯШЬТӘШЛӘРЕ БЕЛӘН ЭЛЕМТӘЛӘРЕН НЫГЫТА.

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче



# Кытай - Казан арасы

Шушы институтның географик һәм экологик белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы ассистенты Рөстәм Фәрхуллин тырышлыгы белән булачак туризм белгечләре Икътисад һәм финанс, Фундаменталь медицина һәм биология, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты студентлары белән аралашты. Араларында Кытайдан килгән студентлар да бар иде. Алар да шушы институтларда белем эсти. Бу дуслык дәресендә Казан студентлары мәркәзебез, аның тарихы, истәлекле һәм күңел ачу урыннары турында мәгълүмат җиткерде.

Кытай студентлары да буш кул белән килмәгән иде. Алар үз илләре турында презентация, видео һәм фотосюжетлар әзерләгән. Алар ярдәмендә студентлар бик күп мәгълүмат алды. Кытайлылар төрле бәйрәмнәрне билгеләргә ярата икән. Әйтик, фонарь, аждаһа, ай фестивальләре зурлап уздырыла. Кытай халкы этикет кагыйдәләрен буыннан-буынга тапшыруы белән аерылып тора. Алар өлкәннәргә хөрмәт белән карый, традицияләрне, милли тарих һәм әдәбиятны саклый. Студентлар үзләренең артык тыйнак, тыныч холыклы, ягымлы булулары белән таң калдырды. Алар һәр сорауга тулы һәм матур итеп җавап биреп утырды.

Кытайлылар бик аралашучан халык икән. Сөйләшкәндә, «сез» дип бик таныш булмаган һәм өлкән кешеләргә генә эндәшәләр. Аларда исем һәрвакыт фамилиядән соң килә. Исем белән алар бик якын кешеләренә яки туганнарына гына эндәшәләр, ә гомуми аралашуда фамилия кулланыла. Очрашуда Ли Шаодун исемле егет, Тан Цзяити, Чтан Ланьтин исемле кызлар катнашты. Кытайлылар бик кунакчыл халык та. Кунакка килгәндә, үзең белән күп итеп дуслар алып килү гадәти күренеш аларда. Чит ил студентлары безне дә үзләренә чакырды. Тулай торакка гына түгел, ә Кытайга!

Бу илдә хатын-кызлар ир-атлар белән бер дәрәҗәдә: алар да җаваплы вазифаларда эшли ала. Ләкин, Кытай традицияләре буенча, ир-егеткә хатын-кызга кагылырга, аны кулыннан тотарга, өске киемен кияргә ярдәм итешергә ярамый. Шулай ук хатын-кызга урын бирү, аңа ишек ачу гадәтләре юк. Ә гүзәл затларга башкалар янында спиртлы эчемлекләр эчәргә, тәмәке тартырга ярамый.

Кытай студентларының тагын бер зур аермасын күрдем. Алар бөтен җаннары, тәннәре белән белемгә омтыла. Дәрестән соң да китапханәгә барабыз, диделәр. Казандагы дуслары сөйләгән һәр мәгълүматны язып утырдылар. Рус әдипләре турында сүз чыккач, үзләре дә Пушкин, Толстой әсәрләре турында сөйләп бирделәр. Тукаебыз турында да ишеткәннәре бар. Ә без Кытай язучылары турында никадәр хәбәрдар икән соң?

Мондый чаралар ике як өчен дә бик әһәмиятле. Дуслык җепләрен ныгытудан тыш, белемнәрне арттырабыз, кызыклы мәгълүмат ишетәбез. Кытай студентлары да чарадан күтәренке кәеф белән китте. Алар дуслык дәресен уздыручы остазлары Рөстәм Фәрхуллинга чиксез рәхмәтләрен җиткерде.

• Белем баскычлары

# Сабa белән элемтә ныгый

**Альберт БОРҺАНОВ,**
Тарих институты профессоры

Саба халкын кунакчыл дип ишетеп белә идем, күптән түгел моңа шәхсән инанырга туры килде. ТР Фән һәм мәгариф министрлыгы һәм Казан (Идел буе) федераль университеты Саба гимназиясе базасында укучылар өчен фәнни-гамәли конференция уздырды. Чара танылган татар галим-мәгърифәтчесе, академик Ә.Г.Кәримуллин (1925-2000) истәлегенә багышланды.

Конференция Саба якларыннан булган Әбрар Кәримуллинның мәгърифәтчелек эшчәнлеге, калдырган мирасы белән танышу; катнашучыларны рухи кыйммәтләргә, татар халкының милли-мәдәни традицияләренә якынайту максатыннан оештырылды.

ТР Фән һәм мәгариф министрлыгының милли белем бирү һәм төбәкара хезмәттәшлек бүлеге җитәкчесе Раиф Зиннәтуллин, Саба муниципаль районы белем бирү башкарма комитеты бүлеге җитәкчесе Илфат Шакиров катнашучыларны, килгән кунакларны сәламләп, чараны ачып җибәрделәр.



Конференциядә Казан шәһәре, Арча, Балтач, Алексеевск, Алабуга, Саба, Кукмара һәм ТРның башка районнарыннан 8-11 сыйныфларда белем алучы 148 укучы 7 секциягә бүленеп эшләде: «Татар филологиясе», «Рус филологиясе», «Инглиз теле», «Тарих», «Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте» һ.б.

Конференциянең йомгаклау утырышында Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге мөдире, профессор Ф.С.Сәйфулина, XX-XXI гасыр татар әдәбияты һәм укыту методикасы кафедрасы мөдире, профессор Ә.М.Зәкирҗанов, Тарих институты гомуми тарих кафедрасы доценты А.Х.Төхвәтуллин, профессор А.А.Борһанов, «Филология һәм мәдәният» журналының җаваплы мөхәррире М.М.Хабутдинова чыгыш ясадылар. Галимнәр институтлар эшчәнлеге белән дә таныштырды. Казан кунаклары Саба гимназиясе китапханәсенә фәнни китаплар һәм дәреслекләр бүләк иттеләр, шулай ук конференциядә катнашучыларга һәм төбәкне өйрәнүчеләргә диплом һәм грамоталар тапшырдылар.


Әлеге чара КФУның Саба гимназиясе һәм Саба муниципаль районы администрациясе белән традицион хезмәттәшлек күперен ныгытуга зур өлеш кертте.

• Сәяхәттән кайткач

## «Законлы» ял иттек!

**Алинә ХАМАДЬЯРОВА,**
Фундаменталь медицина һәм биология институты

Уку гөрләп торган вакытта кайсы студентка гына «законлы» рәвештә ял итү мөмкинлеге туа икән? Бәхет безгә елмайды. Ник дигәндә, Санкт-Петербургта атна буе кунак булдык.



Укудан качып йөриләр икән дип уйлый күрмәгез! Санкт-Петербург дәүләт университетында «Яшьләр өчен XVI Докучаев укулары» исемле халыкара фәнни конференциядә чыгыш ясау, үзебезнең идеяләребез белән уртаклашу максатыннан юл тоттык без бирегә.

Санкт-Петербург университеты безне җылы каршы алды, безнең дә һәрберебезгә андагы фән мохите бик якын булды. Шунысы куандырды: КФУыбызны анда беләләр һәм югары бәялиләр. Университетыбыз өчен зур горурлану хисләре кичердек.

Шундый ерак аралардан килгәч, шәһәр белән танышмый кайтып китә алмадык. Казан соборын, Эрмитаж, А.С.Пушкин музей-фатирын, Нева елгасы буйларын үз күзләребез белән күрү бәхетенә ирештек!

Сәяхәттән алып кайткан хис-кичерешләребез, тәэсирләребез күңелләребездә озак сакланыр һәм тиздән булачак сессияне җиңел тапшырырга ярдәм итәр дип уйлыйм.

• Универсиаданы каршылап

# Чаба поезд... «Сәламәтлек поезды»

Физик яктан сәламәт кеше генә рухи яктан да сау булырга мөмкин. Академик Н.М.Амосов әйткәнчә, сәламәт булу өчен үзеңнең көчеңне кызганмаска кирәк. Кешеләрнең 50-55 процентының сәламәтлеге – тормыш рәвешенә, 20-25 процентының нәселдәнлеккә, 10-15 проценты сәламәтлек саклау учреждениеләренә бәйле икән. Казан (Идел буе) федераль университеты бу өлкәдә көченнән килгәнчә студентларының сәламәтлеген сакларга тырыша. Ул үткәрә торган «Сәламәтлек поезды» акциясе – яшь буынны актив физик ялга тарту өчен менә дигән чара.

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

## Файдалы ял

Ялларны студентлардан да ныграк сагынып көтүче тагын кемнәр бар икән? Укырга һәвәсләр өй эшләрен эшләп бетерергә ашыга, кемнәрдер телевизор, компьютер алдыннан китә алмый интегә, йокы чүлмәкләре йокысын туйдыра. Зур-зур сумкалар күтәреп, туган ягын сагынып өйләренә кайтучы студентларны автовокзалларда автобуслар көтеп тора. Ә КФУның спортка гашыйк, креатив яшьләрен һәр атна саен «Сәламәтлек поезды» көтә.

Ял көннәре иртәсендә тимер юл вокзалының икенче катында студентлар мәш килә. 1 сентябрь диярсең... Ләкин кулларында чәчәк бәйләме түгел, ә җылы бияләйләр, чаңгы-чаналар. Узган елларның берсендә Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты һәм Телләр институтыннан йөз илледән артык студент һәм хезмәткәр Яшел Үзән шәһәренең «Маяк» спорт үзәгенә юл тотты. Киләсе тукталыш «Яшел Үзән», дустым!



Беренче тапкыр барганга-мы, күңел ниндидер гайре табигый вакыйга көтте. Бер сәгатьлек юл сизелмәде дә. Табигать тә безне күрүенә сөенә: саф, тыныч һава, акрын гына кар ява. Спорт чарасы да бик күңелле башланып китте. Бер-беребезне сәламләп, университет флагын күтәрдек. Аннан соң студентлар чаңгы юлына басты.

Әлеге чаңгы базасы – республикабызда иң яхшы базаларның берсе. Монда бердән алып биш километрга сузылган дистанция үз эченә табигатьнең иң гүзәл почмакларын, таулы урыннарын сыйдырган. Ә чаңгы юлы үзе шуып бара кебек, рәхәтләндек кенә. Бөтен мәшәкатьләрне онытып, табигать кочагына чумдык. Универсиада хөрмәтенә 2013 метрлы дистанцияне дә бик җиңел уздык. 70-80 елларда университетта «Сәламәтлек поезды» еш йөргән. Бүгенге көндә дә әлеге әһәмиятле традицияне сакларга тырышабыз. КФУ студентларына бу ял итү, спорт белән дуслык җепләрен ныгыту өчен бик зур мөмкинлек.

«Әлеге чараның максаты – студентларны сәламәт яшәү рәвешен алып барырга өндәү, быел уздырылачак универсиадага әзерләү, ялларны дөрес, файдалы уздыру. Монда студентлар ярышмый, ә саф һавада рәхәтләнеп аралашалар, танышалар, вакытларын дөрес һәм файдалы итеп уздырырга өйрәнәләр», – ди Математика һәм механика институтының социаль һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары П.Г.Великанов.

Чаңгы шуудан кала, башка күңелле уеннар да оештырылды. Мәсәлән, җәйне сагынган студентлар футбол уйнады, кемдер тезелешеп тауда шуды, кемдер рәхәтләнеп биеде, җырлады. Тик торырга берсенең дә вакыты булмады. Төшке ашны да дусларыбыз белән саф һавада ашадык. Шуны әйтергә кирәк: юлда бару, прокатка чана-чаңгылар алу, ашау – боларның һәммәсе дә бушлай. Студентлар өчен икеләтә бәхет иде инде бу.

Спорт уеннарыннан соң бергәләп башкарган җырбиюләр аеруча истә калды. Кызганыч, безгә бирелгән вакыт бик тиз үтеп китте, поезд кире юлга кузгалды. Ләкин бүген алган онытылмас мизгелләр, күтәренке кәеф, хис-кичереш, дәрт, ләззәт, бер елга җитәчәк. Казаныбызга кайтканда, безнең дусларыбыз бермә-бер артты. Юл буе бер-беребез белән хис-кичерешләр уртаклаштык.

Бу чараны оештыруда үз өлешен керткән һәр кешегә студентлар исеменнән зур рәхмәт. Без яраттык сине, «Сәламәтлек поезды», кабат очрашуларга кадәр!

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,**
Экология һәм география институты ассистенты

## Саулык иленә сәяхәт

КФУның Экология һәм география институты укытучылары һәм студентлары Яшел Үзәннең «Маяк» спорт комплексында спорт-сәламәтләндерү чарасын оештырган Ариф Межведилов һәм Юлия Виноградова җитәкчелегендәге Социаль һәм тәрбия эшләре буенча Идарәгә чиксез рәхмәтен белдерә. «Сәламәтлек поезды»нда без Физика институтындагы хезмәттәшләребез белән таныштык һәм дуслаштык. Яшел Үзән безне кояшлы матур салкын көн, саф һава, спорт азарты һәм шәп кәеф белән каршы алды. Барлык катнашучыларга спорт уеннарының бик күп төрләрендә үзләрен сынап карау мөмкинлеге бирелде. Студентлар рәхәтләнеп чаңгы, чана шуды, футбол уйнады, канат тартышты. Кемнәрдер кар атышып уйнаса, икенчеләр саф һавада оештырылган дискәтүктә күңел ачты. Коры паек өләшү күтәренке кәефебезне куәтләү өчен бик урынлы булды. Алга таба да мондый чаралар университетыбызның матур гадәтенә әйләнеп китәчәгенә ышанасы килә.



● Экология культурасы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы

# Нәрсә ул экологик культура?

**Җәүдәт ХӨСӘЕНОВ,**
педагогика фәннәре докторы, профессор



Төрле культуралар җыелма рәвештә шәхеснең экологик тәрбиясен барлыкка китерә, аны чын интеллигент итә. Шуңа күрә яшь буынга экология тәрбиясе биргәндә, аңа экология мәгърифәте һәм табигатьне саклау чаралары турында гына сөйләү һич дөрес түгел. Экология культурасының төп нигезләреннән берсе булып, укучыларга тәкъдим ителә торган экология белеме фәне санала.

Әлек-электән үк авылда яшәүче һәр кеше, укый-яза белмәсә дә, табигать телен яхшы аңлаган, күзәтүләр нигезендә табигатьнең серләрен ача алган. Бу белемнәр атадан – балага, бер буыннан икенче буынга мирас итеп калдырылган. Дистә еллар буена күп кенә милли традицияләр юкка чыгу белән беррәттән, халык экологиясенә дә игътибар кимеде, ә бу инде, үз чиратында, табигатькә кешенең тискәре йогынтысы артуга китерде.

Табигатьне күзәтүгә нигезләнгән мәгълүматлар халык авыз иҗатында киң чагылыш тапкан. Әкият, мәкаль, әйтем, сынамыш һәм табышмакларда бик күп экологик белем тупланган. Кыска, ләкин хикмәтле сүзләре белән халык бик тирән мәгънәле фикерләрен әйтеп калдырган. Шуңа күрә дә аларны «ата-баба сүзе» диләр. Мәсәлән, халык акылы болай сөйли: «Җилгә каршы төкермә, сүзең җилгә китәчәк», «Туфракны җир иткән – изгелек күргән, җирне туфрак иткән – ачтан үлгән», «Кәкре агачны төзәтүдән, төз агачны кәкрәйтү җиңел», «Суга сусаган–чишмәчистарткан», «Урман утырткан ачлык күрмәс», «Коега төкермә, суын үзең эчәрсең», «Җир яктысы – кояш белән, кеше яктысы – белем белән», «Белем эштән башлана». Шуңа охшаш мәкаль һәм әйтемнәр яшь буында игелекле эшләр башкарырга омтылыш уята. Алар табигатьне дөрес аңларга булыша, экологик культура тәрбияләүгә җирлек әзерли.

Бала беренче белемне гаиләдә туплый, аннан балалар бакчасында, мәктәптә ала, аңа әтиәнисе булыша, тирә-юньдәге кешеләр ярдәм итә. Ул әлеге белемнәрне төрле китаплардан, өстәмә мәгълүматны интернет челтәреннән таба. Телевидение аерым каналлар аша даими рәвештә дөньякүләм табигать серләрен ачып тора, әйләнә-тирә мохитне күзаллауны киңәйтә, табигать һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне киңрәк аңларга, тагын да күп белергә ярдәм итә. Бу хакта күренекле педагог В.А. Сухомлинский: «Табигатьне яраткан кеше аңа хезмәт итмичә яши алмый», – дип язган. Мондый мәгълүматлар балаларда табигатькә карата сак караш булдырырга, аңа мәрхәмәт белән карарга ярдәм итә.

Ф.Бэкон язганча, «Белем ул – көч, көч ул – белем». Ләкин шунысын билгеләп үтү кирәк, күренекле рус язучысы Л.Толстой фикеренчә, «Әхлакый нигездән башка белем бернигә дә ярамый». Кызганычка каршы, соңгы вакытларда мәктәпләрдә нәкъ шушы «әхлакый нигезгә» игътибар нык кимеде кебек.

Безнеңчә, мәктәптә ала торган фәнни белемнән тыш, укучы бала халыкның экология белемнәренә дә ия булырга тиеш. Бу очракта аңа халыкның экология педагогикасын үзләштерү кирәк. Экология педагогикасына халыкның табигать күренешләре закончалыкларын аңлатуга һәм андагы бәйләнешләрне чагылдыруга караган белемнәр керә. Әлеге белемне санга сукмау кешелек җәмгыятенә зур зыян китерә. Моңа мисал итеп, халыкның түбәндәге хикмәтле сүзләрен китерергә мөмкин: «Белмичә утыртылган агач тиз корый», «Кое казыган кешегә су бирмичә ярамый», «Кое кибеп бетмичә, без суның кадерен белмибез», «Эчкән чишмәңә пычрак ташлама», «Пычрак елгада чиста су булмый», «Саф чишмәдән агып чыкса, елга да чиста була».

Халыкның экология педагогикасы казанышларын табигать белеме һәм гуманитар фәннәрне укытканда һәм сыйныфтан тыш тәрбия чараларында куллану мөмкинлеге зур. Нәкъ шундый белемнәр табигать дөньясы белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәт һәм бәйләнешләрне ныгыта, табигый ресурсларны рациональ файдалануның фәнни нигезен тәшкил итәләр. Шундый белемнәрне үзләштергән укучылар үзләрен табигатьнең бер компоненты итеп сизәләр, әлеге белемнәрнең никадәр әһәмиятле икәнен аңлыйлар, табигатьне саклауга һәм яклауга үз өлешләрен кертәләр. Моны без яшь буынның экология культурасына таба чираттагы адымы дип саныйбыз. Бу очракта алар табигатькә карата сакчыл караш күнекмәләре алалар, үзләре үк мәктәп, гимназия, лицей, район, шәһәр һ.б. күләмендә табигатьне саклау чаралары оештыралар.

Шулай итеп, педагог, остаз буларак, балаларга фәнни һәм халык экологиясе белемнәрен бирә, әлеге белемнәр нигезендә аларда экология культурасы булдырырга ирешә. Нәтиҗәдә укучы балалар аңлы рәвештә табигый-социаль шартларны яхшырту эшенә үзләреннән өлеш кертергә тырышалар.

● Студент эш эзли

# Диван сатам, кем ала?

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты

Студент кайчан да студент. Аңа һәрвакыт эш һәм акча кирәк. Эшнеңояты юк, диләр. Шулай дидем дә, укудан бушаган вакытта гына булса да эшләп, акча юнәтеп алырга булдым.

Эш урыным – Казандагы йорт җиһазлары кибетләренең берсе. Һөнәрем – сатучы-консультант. Безнеңчә, сатучы-киңәшче була инде. Ә киңәш сорап мөрәҗәгать итүчеләр аз түгел. Хәер, бу хакта соңрак.

Берәүләр: «Сатучы булуның ние бар? Алучы булса, товарны озату авыр түгел инде», – дип уйлыйдыр. Элек мин дә шундыйрак фикердә идем. Әмма үз башыма төшкәч, моның бер дә алай түгеллеген аңладым.

Мин эшли торган сәүдә үзәгендә йомшак җиһазлар белән сату иткән нокталарның саны бихисап. Кыскасы, конкуренция – менә дигән! Шуңа да башкаларныкын түгел, ә нәкъ менә синең диваныңны алсыннар өчен, бүтәннәргә караганда өлгеррәк, җитезрәк була белергә кирәк.

«Тел бистәсе» булсаң, икеләтә әйбәт. Кызыксынып килгән сатып алучыга син сата торган йомшак җиһазның иң уңайлы, иң сыйфатлы, иң яхшысы икәнен төшендерү, ай-яй, җиңел эш түгел. Әмма вакыт һәм сәүдә йортының махсус коуч-тренерлары (сату итәргә өйрәтүче махсус кешеләр) ярдәмендә монысына да өйрәнеп булганлыгын аңладым. Иң элек үзем сата торган товар, аны җитештерүчеләр һәм конкурентлар хакындагы мәгълүматны тулысынча өйрәнергә туры килде.

Сәүдә итүнең махсус баскычлары да бар икән: клиент белән элемтәгә керү, аның таләпләре хакында төгәлрәк белү, товарны тәкъдим итү, клиентның ризасызлыкларын исәпкә алу, аның шикләнүләрен бетерү һәм соңгысы – сату итүне төгәлләү. Нәзари яктан бернинди авыр нәрсә юк кебек инде. Әмма... тормышта бөтенләй башкача килеп чыга шул. Сату этаплары да еш кына бер-бер артлы түгел, ә буталган рәвештә тезелә. Кайбер сатып алучылар белән исәнләшергә өлгермисең, шунда ук үз ризасызлыкларын белдерергә ашыгалар. Ирексездән аның товарга карата туган шикләнүләрен бетерү этабына кереп китәргә туры килә.

Җиһаз – ипи түгел, көн саен алмыйлар. Шуңа аны сатып алырга теләүчеләр бик күп кибетләрне, сәүдә нокталарын иңли. Диван-кәнәфиләрнең сыйфаты, бәясе белән таныша, аларның уңай һәм тискәре якларын чагыштыра. Бу – клиентның өлгерү чоры. Ә сайлап алу мөмкинлеге чыннан да зур: бүген җиһазның ниндиен генә ясамыйлар – төрле тукымадан, чын яки ясалма күннән тегелгәннәре, ике, өч, дүрт, биш урынлы, почмаклы яки махсус ял итә торган йомшак җиһазлар... Акчаң гына булсын.

Әмма сатучы-консультантка диван һәм кәнәфи төрләре хакында белү генә аз икән әле. Җиһаз модельләренең нинди шартларда отышлырак күренүен билгеләргә дә кирәк – монысын үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Клиент килә дә, еш кына бик буталчык итеп, диванның фатирның кай урынында торачагын, аның нинди дизайнда булырга тиешлеген аңлата башлый. Әнә шул сурәтләүләрдән генә сатып алучының яшәү урынын күз алдына китереп, аңа нәкъ менә нинди җиһаз сайларга кирәклеге хакында киңәш бирәсең, клиентны канәгатьләндергән дизайн вариантын тәкъдим итәсең. Җиһаз салонында сатучы моның барысын күз дә йоммый эшли белергә тиеш.

Күпмедер дәрәҗәдә психолог булырга да туры килә, чөнки, сәүдә итү – сатып алучыны «сиңа нәкъ менә шушы әйберне алырга кирәк», – дип ышандыру, инандыру ул. Гадәти аралашу кагыйдәләрен үтәү һәм төрле кешеләр белән уртак тел таба белү – сатучы-киңәшчегә кирәкле сыйфатларның чираттагылары. Һәр кеше үзенә хөрмәт, игътибар күрсәткәнне ярата. Сатып алучылар да бу кагыйдәдән искәрмә түгел. Шуңа аларга диван-кәнәфинең сыйфатламасын чит тел сүзләре белән түгел, гади «халык» телендә аңлату отышлырак. Эш барышында моның шулай икәнлегенә күп тапкыр инандым.

Ахыр чиктә, сатучы-киңәшче чын мәгънәсендә сәүдәгәр, алып-сатар булырга тиеш. Ник дигәндә, хезмәт хакың турыдан-туры товарның сатылу дәрәҗәсенә бәйле бит. Һәр сатылган җиһаздан билгеле бер күләмдәге акча синең кесәңә керә. Хезмәте каты – җимеше татлы, дигәндәй, беренче эш хакымны алгач, күңелләр күтәрелеп куйды. Студент аз гына керемгә дә шатлана бит ул. Бер айга гына булса да әти-әни җилкәсеннән төшеп торуыңны тою – үзе бер рәхәт. Өстәвенә, яңа һөнәргә өйрәнү беркайчан да комачауламый. Бер иптәш кызым әйтмешли, карбыз сатучы булуның да үз мәнфәгате бар – ахыр чиктә иң татлы җимешне сайларга өйрәнәсең.

● Киңәш-табыш

# Егылырга өйрәнәбез!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Язга керсәк тә, кыш үзенекен итә әле. Һава торышы да гел үзгәреп тора: бер көнне кояш яктырак балкый, түбәдән тамчылар тама, икенче көнне буран котыра. Әмма аяк астының бер җебеп, бер катырып урамда чын шугалак ясавы бераз проблемалар тудыра...



Елның нәкъ шушы чорында егылып имгәнү, кул яисә аякны сындыру очраклары арта. Тротуар, тукталыш, кибет, метро баскычлары, йорт ишегалды – кешеләрнең иң еш егыла торган урыннары. Мондый күңелсезлекләргә юлыкмас өчен, берничә гади киңәшне истә тотарга кирәк:

✦ тайгалактан барганда, бик игътибарлы булырга һәм башка эшләр белән (телефоннан сөйләшү, көзгегә карау һ.б.) шөгыльләнмәскә. Үзегезне кулда бәллүр савыт тотып барган кебек хис итегез;

✦ аягыгызга нык басып һәм һәрвакыт алдыгызга карап йөрегез. Аякларыгызны катырмагыз һәм тездән бераз бөгеп атлагыз;

✦ аяк киемен дә дөрес сайларга кирәк. Бу бигрәк тә хатын-кызларга кагыла. Яхшы кышкы аяк киеме тигез табанлы, таймый торган материалдан һәм рельефлы бизәк төшереп ясалган булырга тиеш. Елның салкын фасылында асыл затларга биек үкчәле, зур платформалы аяк киеменнән тыелып тору киңәш ителә. Таеп егылмас өчен халык дә кулланырга мөмкин. Мәсәлән, аяк киеме табанына медицина пластыре яисә шомартылган кәгазь ябыштырырга була. Һәр спорт кибетендә тайгалакта аяк киеменә беркетелә торган махсус җайланмалар бар. Алар бик чыдам һәм озакка җитә;

✦ кулларны кесәгә тыгып йөрмәгез. Андый халәт тайгак урында тигезлекне сакларга комачаулый.

Әгәр егылудан котылып булмаса, түбәндәгеләрне эшләргә тырышыгыз:

✦ кисәк утырыгыз. Алай эшләгән очракта, авырлык үзәге авыша һәм

✦ терсәкләне ян-якка таба кысарга, башны мөмкин булган кадәр җилкәләргә якынайтырга, арканы туры тотарга тырышыгыз. Әгәр баскычтан егылып төшсәгез, кулларыгыз белән бит һәм башны каплагыз. Егылмый калмаска тырышу урынлы булмаячак. Бу сынулар санын арттырачак кына;

✦ егылган очракта кулларны алга таба сузарга да киңәш ителми.

Егылсаганнан соң, берәр төрле авырту борчый икән, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әгәр җиңелчә генә имгәнү алган булсагыз, авырткан җиргә салкын әйбер куярга яки махсус мазьгельләр сөртергә була.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.